| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

19.11.2021 г.Зеленодольск № 115

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 20 маендагы 495 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны, җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 3 июнендәге 73 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

2021 елның 11 июнендәге «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 191-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясына үзгәрешләр кертү белән бәйле, 2021 елның 1 июлендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 28 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 289-ФЗ номерлы Федераль закон белән, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы, **карар итте:**

1.Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 20 маендагы 495 номерлы карары белән расланган,Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны һәм җәмәгать фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 3 июнендәге 73 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1 өлешендә «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2018 елның 29 мартындагы 279 номерлы карары белән расланган, » сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 7 статьяның 2 өлешендәге 1 пунктында «гавами тыңлаулар билгеләү турында» сүзләреннән соң «муниципаль хокукый акт проекты»сүзләрен өстәргә;

1.3. 7 статьяның 3 өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Гавами тыңлауларда катнашучылар муниципаль хокукый акт проекты буенча фикер алышуга чыгарылган үз тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен, шул исәптән гавами тыңлаулар узган көндә дә рәсми сайт ярдәмендә, тапшырырга хокуклы.»;

1.4. 9 статьяның 5 өлешен түбәндәге эчтәлекле 6.1 пункт белән өстәргә:

«6.1) кабул ителгән карарны дәлилләп нигезләү;»;

1.5. 11 статьяның 3 өлешендәге 2 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2) иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы адресына язмача яки электрон документ рәвешендә;»;

1.6. Нигезләмәнең 3 нче кушымтасында «Җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүнең йомгаклау варианты: __________ » сүзләреннән соң «кабул ителгән карарларны дәлилләп нигезләү» сүзләрен өстәргә;

1.7. Нигезләмәнең 4 нче кушымтасында 2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

2) җәмәгать фикер алышуларын оештыручы адресына язмача яки электрон документ рәвешендә яисә электрон документ формасында______________адресы буенча ;»

1.8. Нигезләмәнең 5 нче кушымтасында 1)пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«1) җәмәгать фикер алышуларын оештыручы адресына язмача яки электрон документ рәвешендә;».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарны контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы, Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА ИНН 1648017831 КПП 164801001 ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ